

Галия Раис кызы Зиниковага чын шедеврлар булдыру очен коч, илһам һәм унай эмоцияләре житә. Бvген, мә-дәниятне саклаучы, безнен кvренекле костюм остасы - Галия Раис кызынын эше турында сойләп vтәсе килә.

Кеше гомеренен зур олешен эштә vткәрә. Бу зур олешнен табыш китерvе генә тvгел, ләззәт алып килvе дә яхшы.Тагын да яхшырак эш - ул хобби, Анда син ихлас йорәктән гашыйк эшенә чумасын. Хобби булсын дисән, vз һо-нәренә тормышка ашсын очен талант, эшкә мәхәббәт һәм vжәтлек бик кирәк.Рузаевканын «Үзәк клуб»ына килгән тамашачылар теләсә кайсы мәдәни чарага әзерлек процессынын никадәр авыр һәм озак вакытка сузылуы турында уйламый.        Костюмер роле дә, беренче карашка, ботенләй сизелми - бу бер яктан. Ә икенче яктан – артистларга, кабатланмас сәхнә образлары тудыру очен, алыштыргысыз нәрсә ул - костюм. Әмма чаранын унышы әлеге белгечнен сәнгати зәвыгына бәйле. Барлык артистлар да vз эшенен остасы Галия Раис кызы куллары белән ясалган якты, матур, сәхнә костюмнарында чыгыш ясый.
Кем сон бу унган костюмер дигән сорау туа. Галия Раис кызы Рузаевка шәһәрендә туа, 10 нчы урта мәктәпне тә-мамлый. Балачакта хорда жырлый, тегv белән мавыга. Үзенен ижади һонәрен ул Казан урта һонәри училищесында «Югары хатын-кыз киемнәре тегvчесе» белгечлеге буенча ала. Буш вакытында бассейнда йозәргә ярата. Традицион костюмнардагы курчаклар коллекцияли.
2003 елдан Рузаевка шәһәре клубында (МБУК «ЦК») костюмер булып эшли. 20 ел дәвамында ул 400 гә якын костюм комплекты ижат иткән. Галия Раис кызы сәхнә киемен оста саклый: чистарта, вак-тояк ремонт ясый. Костюмнар һәм аларнын реквизитларын саклап, аларны табып була. Ул барлык торләрен, маркаларын, кvләме һәм башка костюм

vзенчәлекләрен, аксессуарларны һәм реквизитларны беләә.
Галия Раис кызы очен клубтагы костюмер эше - ботенләй эш тvгел, ә яшәv рәвеше, анын мәгънәсе. Анын куллары алтын, ул оста һәм уйлап табучы. Галия Раис кызы Зиникова - эш кешесе, профессионал, хормәткә лаек кеше.
Гаиләсенә дә кvз тимәсен, матур. Унган Галия Раис кызы тормыш иптәше Ильдар Рафаэль улы белән кызлары Дианага тиешле тәрбия биреп vстерәләр, белем бирәләр. Бvген кызлары Зубово-Поляна районындагы Явaста погонлы хезмәткәр. Алда сезне унышлар котсен!

**Наилә НАСЫРОВА**